МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 18/о

П Р И К А З　　　　Б О Е Р Ы К

« 08 » 02 2021

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының аерым боерыкларын гамәлдән чыккан дип тану турында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының түбәндәге боерыкларын гамәлдән чыккан дип танырга:

«Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләргә, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге, үзләренә беркетелгән торак урыны булмаган затларга бирелә торган сертификат бланкларын тутыру тәртибен раслау турында» 2008 елның 30 маендагы 80/о номерлы;

«Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләргә, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге, үзләренә беркетелгән торак урыны булмаган затларга бирелә торган сертификат бланкларын исәпкә алу, саклау һәм юк итү тәртибен раслау турында» 2008 елның 30 маендагы 81/о номерлы;

«Сертификат бланкы формасын раслау турында» 2017 елның 22 мартындагы 61/о номерлы.

2. Юридик бүлеккә, дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

Министр　　　　М.М.Айзатуллин